ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2025ел № 10223

Башкарма комитетның «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 22 сентябрендәге 8870 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 22 сентябрендәге 8870 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2024 елның 1 мартындагы 1323 номерлы, 2024 елның 19 декабрендәге 8478 номерлы, 2025 елның 14 мартындагы 1984 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 21823,51 мең сум: 2024 ел — 6528,91 мең сум, 2025 ел — 7647,30 мең сум, 2026 ел — 7647,30 мең сум күләмендә» сүзләрен «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 21825,61 мең сум: 2024 ел — 6528,91 мең сум, 2025 ел — 7649,40 мең сум, 2026 ел — 7647,30 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары (мең сум) | | | Барлыгы (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | |
| | муниципаль бюджет | 6528,91 | 7649,40 | 7647,30 | 21825,61 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| чыганаклары | республика бюджеты | - | - | - | - |
| | федераль бюджет | - | - | - | - |
| | башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | барлыгы | 6528,91 | 7649,40 | 7647,30 | 21825,61 |

- 5 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

- 6 бүлектә «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 21823,51 мең сум: 2024 ел — 6528,91 мең сум, 2025 ел — 7647,30 мең сум, 2026 ел — 7647,30 мең сум күләмендә» сүзләрен «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 21825,61 мең сум: 2024 ел — 6528,91 мең сум, 2025 ел — 7649,40 мең сум, 2026 ел — 7647,30 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 5 декабрендәге
10223 номерлы карарына
кушымта

5 бүлек. Программа кысаларында үткәрелә торган чаралар

| № т/б | Чараның исеме | Башкаручылар | Төп чаралар ны үтәү срок лары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2024 | 2025 | 2026 |
| Максатның исеме: җирле үзидарә органнары тарафыннан йөкләнгән вәкаләтләрне муниципаль хезмәт идарәсе системасын камилләштерү юлы белән үтәү нәтиҗәлелеген күтәрү | | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрү | | | | | | | | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының Бердәм мәгълүмат системасында кадрлар эшен алып баруны тәэмин итү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе, Башкарма комитетның гомуми бүлеге | 2024-2026 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасында җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлый торган актуаль мәгълүматлар булу | + | + | + | + | - | - | - |
| Бурычның исеме: муниципаль хезмәткә яшь, перспективалы белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү | | | | | | | | | | | |
| 2. | Яр Чаллы шәһәре рәсми сайтында һәм | Башкарма комитетның персонал белән эшләү | 2024-2026 еллар | муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары | + | + | + | + | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Дәүләт хезмәте һәм идарә кадрлар федераль порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат урнаштыру | һәм муниципаль хезмәт идарәсе | | турында мәгълүмат булу:<br>1) муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында;<br>2) «Дәүләт хезмәте һәм идарә кадрлар федераль порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында | | | | | | |
| 3. | Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеге турында мәгълүмат бастыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2024-2026 еллар | массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында бастырып чыгарылган мәкаләләр һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар саны | 20 | 20 | 22 | 22 | - | - | - |
| Бурычның исеме: Муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы тору чараларын тормышка ашыру системасын үстерү | | | | | | | | | | |
| 4. | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт үтүгә бәйле | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2024-2026 еллар | үткәрелгән тикшерүләр һәм башка чараларның саны | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны, шул исәптән коррупциягә каршы тору буенча законнарны үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: Муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ һәм идарә итү компетентлылыгын үстерү | | | | | | | | | | | |
| 5. | Муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ үсеше, шул исәптән өстәмә профессиональ белем бирү (квалификация күтәрү, яңадан профессиональ әзерлек) буенча чаралар оештыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2024-2026 еллар | тиешле елда квалификация күтәрү, яңадан профессиональ әзерлек үткән муниципаль хезмәткәрләрнең өлеше, штат саны % | 33 % | 33 % | 33 % | 33 % | 1916,15 (муниципаль бюджет) | 2442,00 (муниципаль бюджет) | 2442,00 (муниципаль бюджет) |
| 6. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләренең стажировка мәйданчыкларын оештыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе,<br>Башкарма комитетның финанс идарәсе,<br>Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, | 2024-2026 еллар | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләре үткән стажировкалар саны | 3 | 3 | 3 | 3 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның алгарышлы үсеш территориясен үстерү бүлеге | | | | | | | | |
| 7. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең идарә кадрлары резервын формалаштыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2024-2026 еллар | җирле үзидарә органнарында идарә вазыйфаларына резервка кертелгән гражданнарның саны | 28 кеше | 28 кеше | 28 кеше | 28 кеше | - | - | - |
| 8. | «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы кысаларында муниципаль хезмәткәрләрне укытуның нәтиҗәлелеге мониторингында катнашу | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2024-2026 еллар | «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенә уткәрелә торган укытуның сыйфаты турында мәгълүмат, муниципаль хезмәткәрләрне укыту системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр җибәрү | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурычның исеме: муниципаль хезмәттә мотивацияләү, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү | | | | | | | | | | | |
| 9. | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәре» конкурсын оештыру һәм үткәрү һәм тиешле республика һәм бөтенроссия конкурсларында катнашуга тәкъдим итү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2024-2026 еллар | муниципаль хокукый акт кабул итү һәм «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәре» конкурсын үткәрү | + | + | + | + | 104,16 (муниципаль бюджет) | 100,00 (муниципаль бюджет) | 100,00 (муниципаль бюджет) |
| 10. | Муниципаль хезмәткәрләрне һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен диспансеризацияләүне үткәрү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2024-2026 еллар | җирле үзидарә органнарының диспансеризацияләү үткән хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләре саны, кеше | 391 | 395 | 400 | 400 | 1196,24 (муниципаль бюджет) | 1500,00 (муниципаль бюджет) | 1500,00 (муниципаль бюджет) |
| 11. | Муниципаль хезмәткәрләрнең эш урыннарын тәртипкә китерү һәм матди-техник җиһазлауны модернизацияләү | Башкарма комитетның гомуми бүлеге | 2024-2026 еллар | җирле үзидарә органнары эшчәнлеген мәгълүмати, административ-хуҗалык һәм матди-техник яктан тәэмин итүне һәм оештыру шартнамәләр булу | + | + | + | + | 2000,00 (муниципаль бюджет) | 2000,00 (муниципаль бюджет) | 2000,00 (муниципаль бюджет) |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12. | Муниципаль хезмәткәрләрне мәҗбүри дәүләт иминләштерүен үткәрү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2024-2026 еллар | җирле үзидарә органнарының иминләштерелгән муниципаль хезмәткәрләре саны, кеше | 543 | 523 | 605 | 605 | 1181,86 (муниципаль бюджет) | 1474,80 (муниципаль бюджет) | 1474,80 (муниципаль бюджет) |
| 13. | Җирле үзидарә көненә һәм Финансистлар көненә багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2024-2026 еллар | муниципаль-хокукый актлар кабул итү һәм Җирле үзидарә көненә һәм Финансистлар көненә багышланган чаралар үткәрү | + | + | + | + | 130,50 (муниципаль бюджет) | 132,60 (муниципаль бюджет) | 130,50 (муниципаль бюджет) |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева